**Каралды**
**Методик берләшмә җитәкчесе**
**______ Рамазанова Р.Н.**
**Беркетмә № 1**
**25 нче август 2017 нче ел**

**Килешенде**
**Уку-укыту эшләре буенча**
**директор урынбасары**
**______ Г.Т.Исмагилова**
**28 нче август 2017 нче ел**

**Раслыйм**
**Мәктәп директоры**
**________ Г.Т.Сабирзянова**
**Приказ № 71**
**28 нче август 2017 нче ел**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**
**“Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе” татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Рамазанова Раушания Наил кызының**
**9 нчы Б,В сыйныфы өчен татар әдәбиятыннан**

# ***ЭШ ПРОГРАММАСЫ***

**Педсовет утырышында каралды**
**Беркетмә №1 28 нче август 2017 нче ел**

**2017-2018 нче уку елы**

# **Татар әдәбиятыннан эш программасына аннотация**

9 нчы класс

**Программаның исеме:**
6нчы сыйныф өчен татар әдәбиятыннан эш программасы.
**Программаны төзүче**: Хатипова Гөлназ Рафис  кызы

Укыту фәненең белем бирү программасы структурасында алган урыны:
Татар теле “Филология” белем бирү өлкәсенә керә.
Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен әдәбиятыннан **программа** (5-11 нче сыйныфлар). – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.
**Дәреслек:** Әдәбият: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек/ Ф.Ә.Ганиева, М.Д.Гарифуллина – Казан: Мәгариф, 2014.
**Программаны үтәү вакыты:** 2017 –2018 нче уку елы
**Сәгать саны**: Атнага 2сәгать–барлыгы 68 сәгать
**Укучылар үзләштерергә тиешле осталык һәм күнекмәләр (уку елы ахырына):** әдәбиәсәрдәгеэпизодларныһәмгеройларнычагыштыру, автор позициясеначыклау;.
**Контроль төрләре:** сорауларга җавап бирү, тест, мөстәкыйль эш, чирек ахырында контроль эшләр.

## Аңлатма язуы

Программа нигезенә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыкларының мәктәпләрдә урта һәм тулы белем алу стандартлары алынды.
Программа түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп төзелде:
1.”Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 нче ел, 1 нче июль).
2. "2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы” (2004 нче ел, 11 нче октябрь).
3. Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007 нче ел, 1 нче декабрь).
4. Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы. – Казан, 2008.
5. Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары (5-11 нче сыйныфлар) -Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.
6. «Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең 2017-2018 нче уку елына укыту планы.

Эш программасы мәктәпнең укыту планындагы дәресләр бүленешен исәпкә алып төзелде.Мәктәпнең укыту планында 9 класска әдәбияттан атнага 2 сәгать каралган. Эш программасы да атнага 2 сәгать исәбеннән 68 дәреслек итеп төзелде. Дәресләр шуңа нигезләнеп бүленде.

**9 нчы сыйныфта татар әдәбияты укытуның максатлары:**

1. Татар әдәбиятының тарихи барышы турында гомуми караш булдыру.
2. Татар әдәбиятының барышын, аның борынгы һәм урта гасырдагы, 17, 18 нче, 20 нче гасыр башы чорындагы торышын, чор әдәбиятының йөзен билгеләүче язучылар иҗатын анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.
3. Әдәби-теоретик белемнәр нигезендә әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының, гомумән, татар әдәбиятының үзенчәлекләрен табарга күнектерү.
4. Текст һәм башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны ала белү һәм аны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү.
5. Иҗади фикерләүдәге уртак һәм милли үзенчәлекләрне танырга өйрәтү.
6. Укучыда кызыксыну хисен уяту, белем алуга, иҗади һәм рухи үсүгә теләк – омтылыш тудыру, укучының иҗади сәләтен үстерү.
7. Әдәбият тарихы турында билгеле күләмдә белем бирү. Әдәбиятны чор белән бәйләп, үсештә карау.
8. Әсәрне язучы иҗат иткән чор белән, шул чор әдәбиятының уртак, гомуми сыйфатлары белән бәйләп аңлату, анализлау – әдәбият тарихы турында мәгълүмат бирү.

**Бурычлар:**

1.Өйрәнелгән әдәби әсәрләрне чорларның үсеш тәртибендә системалы итеп күзалларга ярдәм итү.
2.Әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен, төрен һәм жанрын билгеләргә өйрәтү.
3.Әдәби әсәрне анализлау күнекмәләре булдыру.
4.Шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрләрдән өзекләрне ятлату.
5.Укучының мөстәкыйль фикерләвен, гомумиләштереп нәтиҗәләр ясау сәләтен үстерү.
6.Бәхәсләрдә катнашу, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларыңны раслау һәм дәлилләү күнекмәләре булдыру.
7.Рефератлар, докладлар әзерләргә өйрәтү.
8.Әдәби әсәрләр һәм ирекле темалар буенча сочинение язу күнекмәләрен үстерү.

9.Әдәбият теориясе, әдәбият тарихы, сәнгатьнең башка төрләре бергәлегендә укучыда әдәбиятны мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият-сәнгать белән даими кызыксыну тәрбияләү.
10.Матур әдәбиятта халык тарихы, милләт язмышы гәүдәләнешенә укучыларның игътибарын туплау.
11.Әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен, поэтикасын аңларлык эстетик зәвык булдыру.
12.Укучыларда кешелеклелек, горурлык, үз кадереңне белү хисләре тәрбияләү

**Укыту-тематик планы**

| № п/п | Бүлекләр | Барлык сәгатьләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Ничә дәрес | Дәрестән тыш уку | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Барлыгы |
| 1 | Кереш. Тарихи-әдәби процесс һәм аның үзенчәлекләре. Матур әдәбиятның кеше тормышында тоткан урыны | 1 | | | 1 |
| 2 | Татар-төрки әдәбиятының чыганаклары. Рун язулы истәлекләр. Уйгур язулы истәлекләр. Гарәп язулы истәлекләр: М.Кашгарый “Диване лөгатет-төрк”, Й.Баласагунлы “Котадгу белек” | 2 | | | 2 |
| 3 | Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани иҗатлары турында кыскача мәгълүмат бирү. | 1 | | | 1 |
| 4 | Коръән. Ислам дине һәм төрки-татар мәдәнияте. <u>Әдәбият теориясе.</u> Шәрекъ классикасы. | 1 | | | 1 |
| 5 | Болгар чоры әдәбияты. Кол Гали турында белешмә. “Кыйссаи Йосыф” поэмасы | 4 | 1 | 1 | 6 |
| 6 | Алтын Урда чоры әдәбиятына күзәтү. Суфичылык. С.Сараиның тәрҗемәи хәле, иҗаты. | 4 | 1 | | 5 |
| 7 | Казан ханлыгы әдәбияты. “Идегәй” дастаны. Мөхәммәдьяр. “Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур” поэмалары. XV-XVI йөзләрдә әдәбиятр. Өмми Кәмал, Мөхәммәт Әмин, Кол Шәриф, Шәрифи иҗатлары турында кыскача мәгълүмат. | 3 | 2 | 1 | 6 |
| 8 | XVII йөз әдәбияты. “Дәфтәре Чыңгызнамә”, “Гайса углы Амәт”, “Җәмигъ-әт-тәварих” әсәре турында мәгълүмат. Мәүла Колый.“Хикмәтләр”е. Габди иҗаты. | 3 | | | 3 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9 | XVIII йөз әдәбияты, әдипләре. Габдессәлам, Г.Мөслим углы, Әхмәдбик, Т.Ялчыгол һ.б. язучыларның иҗатларына күзәтү. Г.Утыз Имәни. | 4 | | | 4 |
| 10 | Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятына йомгак. <u>Әдәбият теориясе.</u> Тарихи-әдәби процесста әдәби бәйләнешләрнең роле. Әдәби иҗатта күчемлелек | 1 | | 1 | 2 |
| 11 | XIX йөзнең беренче яртысында әдәбият. Әбелмәних Каргалый,Салихов, Ш.Зәки-Суфи Г.Кандалый иҗатлары. | 6 | | 1 | 7 |
| 12 | XIX йөзнең икенче яртысындагы татар әдәбияты. Ш.Мәрҗани, Фәезхановларның. К.Насыйриның тормыш юлы. Гыйльми-мәгърифәтчелек эшчәнлеге. | 4 | 1 | 1 | 6 |
| 13 | Реалистик проза үсеше. М.Акъегетнең тормышы, иҗаты. “Хисаметдин менла” романы. Риза Фәхретдиннең. “Әсма, яки Гамәл вә җәза” әсәре. З.Бигиевнең “Мавәрәэннәһердә сәяхәт” әсәре. “Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә” романы | 10 | 1 | | 11 |
| 14 | XIX йөзнең икенче яртысында татар поэзиясе. М.Акмулланың. “Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе” һ.б. әсәрләрен. Гали Чокрый, Я.Емельянов иҗаты. | 5 | | | 5 |
| 15 | Татар драматургиясенең беренче адымнары. Г.Ильяси “Бичара кыз”, Ф.Халиди “Рәдде бичара кыз”. | 2 | | | 2 |
| 16 | IX сыйныфта өйрәнгәннәргә гомуми йомгак. | 1 | | 1 | 2 |
| 17 | Г.Исхакый “Өч хатын белән тормыш” | | 1 | | 1 |
| 17 | Кабатлау һәм имтиханга әзерләнү. | 3 | | | 3 |
| | **Барлыгы** | **55** | **7** | **6** | **68** |

**Эш программасының эчтәлеге**

Кереш. Тарихи-әдәби процесс һәм аның үзенчәлекләре. Матур әдәбиятның кеше тормышында тоткан урыны-1 сәг.

Татар-төрки әдәбиятының чыганаклары. Рун язулы истәлекләр.-1 сәг.

Уйгур язулы истәлекләр. Гарәп язулы истәлекләр: М.Кашгарый “Диване лөгатет-төрк”, Й.Баласагунлы “Котадгу белек”. <u>Әдәбият теориясе.</u> Матур әдәбиятның иҗтимагый вазифасы.-1 сәг.

Йүгнәки, Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани иҗатлары турында кыскача мәгълүмат бирү.-1 сәг.

Коръән. Ислам дине һәм төрки-татар мәдәнияте.- <u>Әдәбият теориясе.</u> Шәрекъ классикасы.-1 сәг.

Болгар чоры әдәбияты. Кереш.-1 сәг.
Класстан тыш уку. М.Хәбибуллин “Кубрат хан” романы.-1 сәг.
Шәхес һәм шагыйрь буларак Кол Гали турында белешмә. “Кыйссаи Йосыф” поэмасының язылу һәм яшәү тарихы.
Әдәбият теориясе. Традиция һәм новаторлык.-1с.
“Кыйссаи Йосыф”ның сюжеты (уку һәм анализлау).-1с.
“Кыйссаи Йосыф”ның төп образлары, идея - проблематикасы.-1с.
“Кыйссаи Йосыф”ның сәнгатьчә эшләнеше, әһәмияте. Поэманы гомумиләштереп анализлау.-1с.
Бәйләнешле сөйләм үстерү.. Сочинение язу.-1с.
Алтын Урда чоры әдәбиятына күзәтү. Суфичылык.-1с.
XIV йөз әдипләре. Рабгузый, Харәзми, М.Болгари, Әхмәд Үргәнчи әсәрләренә күзәтү, өлешчә анализлау.-1с.
Хисам Кятибнең “Җөмҗөмә солтан” әсәрен анализлау.
Класстан тыш уку. Котб “Хөсрәү вә Ширин” .-1с.
С.Сараиның тәрҗемәи хәле. “Гөлстан бит-төрки” әсәрен, “Сөһәйл вә Гөлдерсен” дастанын уку һәм анализлау.-1с.
Казан ханлыгы әдәбиятына кереш. “Идегәй” дастаны-1с.
Класстан тыш уку. Сәйяди “Дастаны Бабахан”.-1с
XV-XVI йөзләрдә иҗат иткән әдипләр. Өмми Кәмал, Мөхәммәт Әмин, Кол Шәриф, Шәрифи иҗатлары турында кыскача мәгълүмат.-1с.
Мөхәммәдьярның тәрҗемәи хәле. “Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур” поэмалары.Әдәбият теориясе. Лирик герой турында төшенчәне киңәйтү. Поэмаларда кеше тормышы һәм табигать күренешләренең чагылышы. Тел-сурәтләү чаралары.-1с.
Бәйләнешле сөйләм үстерү. “Мөхәммәдьяр – гуманист шагыйрь” дигән темага сочинение. -1 сәг.
Класстан тыш уку. Ф.Латыйфи “Хыянәт” романы.-1с.
XVII йөз әдәбиятына күзәтү. “Дәфтәре Чыңгызнамә”, “Гайса углы Амәт”, “Җәмигъ-әт-тәварих” әсәре турында мәгълүмат.-1с.
Мәүла Колыйның тәрҗемәи хәле. “Хикмәтләр”ен уку һәм анализлау.-1с.
Габди иҗаты турында кыскача мәгълүмат. Шигырьләрен уку һәм анализлау.-1с.
XVIII йөз әдәбияты. Тарихи-мәдәни күзәтү. XVIII гасыр татар әдәбиятында жанрлар.-1с.
XVIII йөздә иҗат иткән әдипләр. Габдессәлам, Г.Мөслим углы, Әхмәдбик, Ялчыгол һ.б. язучыларның иҗатларына күзәтү.-1с.
Г.Утыз Имәни. Тәрҗемәи хәле. Иҗатына гомуми күзәтү. Фәнни хезмәтләре.-1с.
Г.Утыз Имәни әсәрләрен уку, анализлау. Әдәбият теориясе. Мәдхия, мәрсия.-1с.
Сочинение язу.-1с.
XIX йөзнең беренче яртысында әдәбиятка күзәтү. Җәмгыять тормышына, мәгърифәт үсешенә тәэсир иткән факторлар.-1с.
Әбелмәних Каргалый иҗаты-1с.
Һ.Салихов, Ш.Зәки-Суфи иҗатларына күзәтү.-1с.
Кандалый – татар әдәбиятында дөньяви поэзияне башлап җибәрүче. “Мулла белән абыстай” шигырен уку һәм анализлау.-1 сәгать.
Кандалый иҗатында дөньяви мәхәббәт. Кандалый реализмы. Хатын-кызларга багышланган поэмалары, шигъри хатлары-1 сәгать.
Кандалыйның татар шигъриятенә, шигырь техникасын баетуга керткән зур өлеше. Әдәбият теориясе. Шигырь үлчәмнәре.-1 сәгать.
Бәйләнешле сөйләм үстерү. Сочинение.- 1 сәгать.
XIX йөзнең икенче яртысындагы татар әдәбиятына гомуми бәяләмә-күзәтү. Ш.Мәрҗани, Фәезхановларның эшчәнлеге һәм иҗаты турында кыскача мәгълүмат бирү.- 1 сәгать
К.Насыйриның тормыш юлы. Гыйльми-мәгърифәтчелек эшчәнлеге.- 1 сәгать.

К.Насыйриның матур әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре.- 1 сәгать.
К.Насыйриның фольклор өлкәсендәге эшчәнлеге. Әдәбият теориясе. Әдәбиятның халыкчанлыгы.- 1 сәгать.
Класстан тыш уку. “Кырык бакча” китабы, “Кырык вәзир” кыйссасы- 1 сәгать.
Бәйләнешле сөйләм үстерү. Сочинение язу. “К.Насыйри үз халкының һәм үз чорының улы булган” (К.Дмитриев)- 1 сәгать.
Реалистик проза үсеше.Әдәбият теориясе. Мәгърифәтчелек реализмы.- 1 сәгать.
М.Акъегетнең тормышы, иҗаты. “Хисаметдин менла” романын уку һәм анализлау- 2 сәгать.
Риза Фәхретдиннең иҗади эшчәнлеге. “Әсма, яки Гамәл вә җәза” әсәрен уку һәм анализлау.- 2 сәгать.
Класстан тыш уку. Ш.Мөхәммәдев “Япон сугышы, яки Доброволец Батыргали агай”.-1 сәгать.
З.Бигиевнең тормышы, иҗаты. “Мавәрәэннәһердә сәяхәт” әсәре. Әдәбият теориясе. Роман жанры.- 1 сәгать.
З.Бигиевнең “Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә” романын уку һәм анализлау.-Әдәбият теориясе. Сюжет, композиция.- 2 сәгать.
Класстан тыш уку. З.Бигиев “Гөнаһе кәбаир” романы.- 1 сәгать.
XIX йөзнең икенче яртысында татар поэзиясе. Гомуми күзәтү- 1 сәгать
М.Акмулланың тормыш юлы, иҗатына күзәтү. “Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе” һ.б. әсәрләрен уку һәм фикер алышу.- 1 сәгать.
Акмулла – чичән шагыйрь. Татар шигъриятенә керткән зур өлеше. Иҗатының әһәмияте.Әдәбият теориясе. Шигырьдә ритм һәм рифма турындагы төшенчәләрне искә төшерү- 1 сәгать
Гали Чокрый иҗатына күзәтү. Әсәрләрен уку һәм анализлау- 1 сәгать
Я.Емельянов иҗаты турында белешмә бирү. “Кайгы”, “Саран бай”, “Олысыманлык” шигырьләрен уку һәм анализлау.- 1 сәгать
Татар драматургиясенең беренче адымнары. Жанр формалашу. Беренче сәхнә әсәрләрендә күтәрелгән мәсьәләләр.Әдәбият теориясе. Драма һәм комедия жанрлары.-1сәгать
Г.Ильяси “Бичара кыз”, Ф.Халиди “Рәдде бичара кыз”. Пьесаларны уку, анализлау-1сәгать
IX сыйныфта өйрәнгәннәргә гомуми йомгак.-1 сәгать
Сочинение.-1 сәг.
Класстан тыш уку Г.Исхакый“Өч хатын белән тормыш”-1сәгать
Киләсе уку елында укылырга тиешле әсәрләргә күзәтү ясау.-1 сәгать. Кабатлау һәм имтиханга әзерләнү.-3 сәг/

Искәрмә. «Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең «Укыту предметы, курсы буенча эш программаларының төзелеше һәм тәртибе” турында» 29 нчы август, 2017 нче елда педсоветта каралган(беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2017 нче елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә һәм каникул көннәренә туры килү сәбәпле, 7 нче сыйныфта программа сәгатьләрне берләштерү исәбенә үтәлә.

.

**Календарь-тематик план**

| | *Тема* | *Укучылар эшчәнлеге төрләре* | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Фактик |
| 1 | Кереш. Тарихи-әдәби процесс һәм аның үзенчәлекләре. Матур әдәбиятның кеше тормышында тоткан урыны. | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗә чыгару, лекция материалын тезислар рәвешендә язу. | 02.09 Б<br>06.09 В | |
| 2 | Татар-төрки әдәбиятының чыганаклары. Рун язулы истәлекләр. “Уйгур-Енисей” ташъязмалары. | Укытучы сүзе, әңгәмә, аңлатмалар бирү, чагыштыру, өзекләр уку, материалны төп фикерләр рәвешендә язу. | 07.09Б<br>08.09В | |
| 3 | Уйгур язулы истәлекләр. Гарәп язулы истәлекләр: М.Кашгарый “Диване лөгатет-төрк”, Й.Баласагунлы “Котадгу белек”. | Укытучы сүзе, сәнгатьле уку, әңгәмә, аңлатмалар бирү, чагыштыру.<br>Мәкальләрне хәзерге телдәге төрдәшләре белән чагыштыру.<br>“Балаларга үгет-нәсыйхәт” китабын тәкъдим итү. | 09.09Б<br>13.09В | |
| 4 | Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани иҗатлары турында кыскача мәгълүмат бирү. | Укытучы сүзе, әңгәмә, аңлатмалар белән уку, сөйләү, чагыштыру. | 14.09Б<br>15.09 В | |
| 5 | Коръән. Ислам дине һәм төрки-татар мәдәнияте.<br>Шәрекъ классикасы. | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару, китап күргәзмәсе алымы, дәреслектәге язмаларның конспектын төзү, сайлап сөйләү.Татар фолькло-рындагы Коръән белән бәйле элементларга мисаллар таптыру. | 16.09Б<br>20.09В | |
| 6 | Класстан тыш уку. М.Хәбибуллин “Кубрат хан” романы. | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару, китап күргәзмәсе алымы, конспектлау. | 21.09Б<br>22.09В | |
| 7 | Болгар чоры әдәбиятына күзәтү. | Яңа китапларга күзәтү ясау. “Иң яраткан китабым” күргәзмәсен оештыру.Әсәр турында фикер алышу, сорауларга җавап табу. | 23.09Б<br>27.09В | |
| 8 | Шәхес һәм шагыйрь буларак Кол Гали турында белешмә. “Кыйссаи Йосыф” поэмасының язылу һәм яшәү тарихы. | Укытучы сүзе, әңгәмә, сорау, нәтиҗәләр чыгару, аңлатмалар бирү. Коръәндәге “Йосыф” сүрәсен “Кыйссаи Йосыф” әсәрендә сурәтләнгән вакыйгалар белән чагыштыру. | 28.09Б<br>29.09В | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9 | “Кыйссаи Йосыф”ның сюжеты (уку һәм анализлау). “Кыйссаи Йосыф”ның төп образлары, идея - проблематикасы. | Эзләнүчән әңгәмә, сөйләү, образларга бәләмә, сүзлек эше, проблемалы анализ, биремнәр эшләү. | 30.09<br>04.10В | |
| 10 | “Кыйссаи Йосыф”ның сәнгатьчә эшләнеше, әһәмияте. Поэманы гомумиләштереп анализлау. | Текст буенча мөстәкыйль эшләү, әңгәмә, биремнәр үтәү, проблемалы анализ, гомумиләштерү. | 05.10Б<br>06.09В | |
| 11 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Сочинение “Кыйссаи Йосыф” поэмасы халыкның рухында. | Аңлату, сөйләү, әңгәмә, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару, иҗади эш алымы, план төзү, аңлатмалар бирү. Сочинениене яза башлау. | 07.10Б<br>11.10В | |
| 12 | Алтын Урда чоры әдәбиятына күзәтү. Алтын Урда чоры мәдәнияте.Суфичылык. | Укытучы сүзе, сүзлек эше, укучыларның докладларын тыңлау, әңгәмә, аңлатмалар бирү (дидактик әдәбият, әдәби багланышлар, әдәби тәрҗемә, газәл, касыйдә, гаруз жанрлары, суфичылык атамасы), дәреслектәге язманың конспектын төзү. | 12.10Б<br>13,10В | |
| 13 | XIV йөз әдипләре. Рабгузый, Харәзми, М.Болгари, Әхмәд Үргәнчи әсәрләренә күзәтү, өлешчә анализлау. | Эзләнүчән әңгәмә, әсәрнең өлешләрен тикшерү, фикерне исбатлау, нәтиҗәләр чыгару, сорау-биремнәргә җавап эзләү, уку. | 14.10Б<br>18.10В | |
| 14 | Хисам Кятибнең “Җөмҗөмә солтан” әсәрен анализлау. | Эзләнүчән әңгәмә, сөйләү, әсәргә проблемалы анализ ясау, стиль үзнечәлекләре. | 19.10Б<br>20.09В | |
| 15 | Класстан тыш уку. Котб “Хөсрәү вә Ширин” . | Эзләнүчән әңгәмә, сөйләү, әсәргә проблемалы анализ ясау, стиль үзенчәлекләре. | 21.10Б<br>25.10В | |
| 16 | С.Сараиның тәрҗемәи хәле. “Гөлстан бит-төрки” әсәрен, “Сөһәйл вә Гөлдерсен” дастанын уку һәм анализлау. | Эзләнүчән әңгәмә, уку, сүзлек эше, сөйләү, әсәрнең өлешен тикшерү, стиль үзенчәлекләрен күзәтү, аңлатмалар бирү (нәзыйрәчелек), чагыштыру. | 26.10Б<br>27.10В | |
| 17 | Казан ханлыгы әдәбиятына кереш. Мәдәнияте. “Идегәй” дастаны.Риваятьләр һәм ле-ендалар.”Иске Казан каласы корылуы”,”Шәһәр ни өчен Казан дип аталган”,”Елан тавы”. | Укытучы сүзе<br>, сүзлек эше, эзләнүчән әңгәмә, биремнәр үтәү, проблемалы анализ, чагыштыру, китап күргәзмәсе алымы. | 28.10Б<br>08.11В | |
| 18 | <u>Класстан тыш уку.</u> Сәйяди “Дастаны Бабахан”. | Эзләнүчән әңгәмә, сөйләү, әсәргә проблемалы анализ ясау, стиль үзенчәлекләре. | 09.11Б<br>10.11В | |
| 19 | XV-XVI йөзләрдә иҗат иткән | Әңгәмә, укытучы сүзе, сүзлек эше, аңлатмалар бирү, нәтиҗәләр чыгару. | 11.11Б | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | әдипләр. Өмми Кәмал, Мөхәммәт Әмин, Кол Шәриф, Шәрифи иҗатлары турында кыскача мәгълүмат. | | 15.11В | |
| 20 | Мөхәммәдьярның тәрҗемәи хәле. “Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур” поэмалары, ”Нәсыйхәт” шигыре. | Эзләнүчән әңгәмә, укытучы сүзе, сора-биремнәргә җавап эзләү, стиль үзенчәлекләрен күзәтү, чагыштыру. | 16.11Б<br>17.11В | |
| 21 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. “Мөхәммәдьяр – гуманист шагыйрь” дигән темага сочинение. | Иҗади эш алымы, план төзү, аңлатмалар бирү. Сочинениене яза башлау. | 18.11Б<br>22.11В | |
| 22 | Класстан тыш уку. Ф.Латыйфи “Хыянәт” романы. | “Ф.Латыйфи иҗатында Казан ханлыгы чорының чагылышы”, “Ф.Латыйфи әсәрләрендә тарихи шәхесләр” дигән темаларга әңгәмә.<br>Сүзлек эше, иҗади уку ысуллары. | 23.11Б<br>24.11В | |
| 23 | XVII йөз әдәбиятына күзәтү. “Дәфтәре Чыңгызнамә”, “Гайса углы Амәт”, “Җәмигъ-әт-тәварих” әсәре турында мәгълүмат. | Укытучы сүзе, сүзлек эше, әңгәмә, аңлатмалар бирү, конспект язу. | 25.11Б<br>29.11В | |
| 24 | Мәүла Колыйның тәрҗемәи хәле. Хикмәтләре : “Юмартлык бу күңелне рушан кылыр...”,”Игенчелек гали эшдер...”, “Гыйлемлелек хак рәхәттер...” | Ээзләнүчән әңгәмә, әсәрне тикшерү, сүзлек эше, уку, сөйләү, әсәрнең телен, корылышын күзәтү, нәтиҗәләр чыгару, сорау-биремнәргә җавап әзерләү. | 30.11Б<br>01.12В | |
| 25 | Габди иҗаты турында кыскача мәгълүмат. Шигырьләрен уку һәм анализлау. | Укытучы сүзе, сүзлек эше, эзләнүчән әңгәмә, сәнгатьле уку, сөйләү. | 02.12Б<br>06.12В | |
| 26 | XVIII йөз әдәбияты. Тарихи-мәдәни күзәтү. XVIII гасыр татар әдәбиятында жанрлар. | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, план, конспект төзү. | 07.12Б<br>08.12В | |
| 27 | XVIII йөздә иҗат иткән әдипләр. Габдессәлам, Г.Мөслим углы, Әхмәдбик, Т.Ялчыгол һ.б. | Укытучы сүзе, сүзлек эше, эзләнүчән әңгәмә, биремнәр үтәү, әдәби әсәрне өлешчә тикшерү. | 09.12Б<br>13.12В | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | язучыларның иҗатларына күзәтү. | | | |
| 28 | Г.Утыз Имәни. Тәрҗемәи хәле. Иҗатына гомуми күзәтү. Фәнни хезмәтләре. | Укытучы сүзе, сүзлек эше, эзләнүчән әңгәмә, биремнәр үтәү, аңлатмалар бирү. | 14.12Б<br>15.12В | |
| 29 | Г.Утыз Имәнинең әсәрләрен уку, анализлау. ”Мәрсия Хәмидә зәүҗәте Габдерәхим Болгари” шигыре, “Мөhиммәтез-заман”поэмасыннан “Йегет булмакның бәяны” бүлеге. | Эзләнүчән әңгәмә, сөйләү, әсәрнең өлешләрен анализлау, стиль үзенчәлекләрен тикшерү. | 16.12Б<br>20.12В | |
| 30 | Борынгы hәм Урта гасыр әдәбиятына йомгак. | Укытучы сүзе, укучыларның чыгышлары, проблемалы ситуацияләрне анализлау, укучыларның чыгыш ясаучыларга сораулары, сорауларга җавап табу, фикер алышу, нәтиҗәләр чыгару. Үз белемеңне тикшерү. | 21.12Б<br>22.12В | |
| 31 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Сочинение ”Утыз Имәни – талантлы шәхес”. | Иҗади эш алымы, план төзү, аңлатмалар бирү. | 23.12Б<br>10.01 | |
| 32 | XIX йөзнең беренче яртысында әдәбиятка күзәтү. Җәмгыять тормышына, мәгърифәт үсешенә тәэсир иткән факторлар. | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару, китап күргәзмәсе алымы, конспект язу. | 11.01Б<br>12.01В | |
| 33 | Әбелмәних Каргалый иҗаты. | Укытучы сүзе, аңлатмалар белән уку, проблемалы сорауларга җавап бирү, әңгәмә. | 13.01Б<br>17.01В | |
| 34 | Һ.Салихов, Ш.Зәки-Суфи иҗатларына күзәтү. | Укытучы сүзе, аңлатмалы уку, проблемалы сорауларга җавап бирү, әңгәмә. | 18.01Б<br>19.01В | |
| 35 | Г.Кандалый – татар әдәбиятында дөньяви поэзияне башлап җибәрүче. “Мулла белән абыстай” шигырен уку hәм анализлау. | Лекция, әңгәмә, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару. | 20.01Б<br>24.01В | |
| 36 | Г.Кандалый иҗатында дөньяви мәхәббәт. Кандалый реализмы. “Сәхипҗамал” поэмасы, шигъри хатлары. | Мөстәкыйль эшләр. Эзләнүчән әңгәмә, шигырьләрне автор артыннан бару юлы белән анализлау, сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйләү, нәтиҗәләр чыгару, сорау-биремнәргә җавап эзләү. | 25.01Б<br>26.01В | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 37 | Г.Кандалыйның татар шигъриятенә, шигырь техникасын баетуга керткән зур өлеше. Шигырьләре: “Йакутлар табыладыр вакыт берлән...”, “Бу илләрдә торып калсам...”Иген икмәк бирер икмәк”.”Бу хәсрәтләр бетәр микән?” | Мөстәкыйль эшләр (тестлар, карточкалар белән эш), укучылар чыгышы. | 27.01Б<br>31.01В | |
| 38 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. **Сочи**нение “Татар поэзиясе үсешендә Габделҗәббар Кандалый иҗатының әһәмияте”. | Бәхәс, әңгәмә, укучылар чыгышы. | 01.02Б<br>02.02В | |
| 39 | XIX йөзнең икенче яртысындагы татар әдәбиятына гомуми бәяләмә-күзәтү. Ш.Мәрҗани, Фәезхановларның эшчәнлеге һәм иҗаты турында кыскача мәгълүмат бирү. | Проблемалы лекция, әңгәмә, план төзү, конспект язу. | 03.02Б<br>07.02В | |
| 40 | К.Насыйриның тормыш юлы. Гыйльми-мәгърифәтчелек эшчәнлеге.”Әбугалисина кыйссасы”. | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару, китап күргәзмәсе алымы, конспект язу. | 08.02Б<br>09.02В | |
| 41 | К.Насыйриның матур әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре.”Фәвакиһел- җөләса-фил әдәбият” | Эзләнүчән әңгәмә, суйләү, проблемалы анализ, биремнәр үтәү. | 10.02Б<br>14.02В | |
| 42 | К.Насыйриның фольклор өлкәсендәге эшчәнлеге. | Эзләнүчән әңгәмә, сәнгатьле уку, сөйләү, аңлатмалар бирү. | 15.02Б<br>16.02В | |
| 43 | Класстан тыш уку. “Кырык бакча” китабы, “Кырык вәзир” кыйссасы. | Эзләнүчән әңгәмә, укучыларның чыгышлары, чагыштыру, тел-стиль үзенчәлекләрен күзәтү. | 17.02Б<br>21.02В | |
| 44 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Сочинение. “К.Насыйри һәм татар халык иҗаты” | Иҗади эш алымы, план төзү, аңлатмалар бирү. | 22.02Б<br>23.02В | |
| 45 | Реалистик проза үсеше. | Проблемалы лекция, әңгәмә, нәтиҗәләр чыгару, дәреслектәге мәкаләнең планын төзү, конспект язу. | 24.02Б<br>28.02В | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 46 | М.Акъегетнең тормышы, иҗаты. “Хисаметдин менла” романын уку һәм анализлау. | Әсәрне автор артыннан бару юлы белән анализлау, укытучы сүзе, сүзлек эше, сюжетны кыскача сөйләү, аерым өлешләргә анализ бирү, аңлатмалар белән уку, әңгәмә. | 01.03Б<br>02.03В | |
| 47 | М.Акъегетнең “Хисаметдин менла” романын уку һәм анализлауны дәвам итү. | Иҗади уку эзләнүчән әңгәмә, әсәрне образлар бирелеше аша анализлау, анализ алымнарын кулланып, әсәрнең эчтәлеген сөйләү, геройларга бәя бирү, сорау-биремнәргә җавап эзләү, тел-стиль үзенчәлекләрен күзәтү. | 03.03Б<br>07.03В | |
| 48 | Риза Фәхретдиннең иҗади эшчәнлеге. “Әсма, яки Гамәл вә җәза” әсәрен уку һәм анализлау. | Укытучы сүзе, сүзлек эше, зсзрне автор артыннан бару юлы белән анализлау, эзләнүчән әңгәмә, сәнгатьле уку, сөйләү, аерым өлешләргә анализ бирү. | 08.03Б<br>09.03В | |
| 49 | Риза Фәхретдиннең “Әсма, яки Гамәл вә җәза” әсәрен уку һәм анализлауны дәвам итү. | Укытучы сүзе, текст өстендә эшләү, әсәргә проблемалы анализ, проблемалы сорауларга җаваплар табу, биремнәр үтәү. | **10.03Б**<br>**14.03В** | |
| 50 | Класстан тыш уку. Ш.Мөхәммәдев “Япон сугышы, яки Доброволец Батыргали агай”. | Эзләнүчән әңгәмә, әсәрне тикшерү, үз мөнәсәбәтеңне белдереп сөйләү, фикерне исбатлау, нәтиҗәләр чыгару. | 15.03Б<br>16.03В | |
| 51 | З.Бигиевнең тормышы, иҗаты. “Мавәрәэннәһердә сәяхәт” әсәре. | Лекция, укучыларның чыгышлары, сәнгатьле уку, сөйләү, әңгәмә, нәтиҗәләр чыгару, китап күргәзмәсе алымы. | 17.03Б<br>21.03В | |
| 52 | З.Бигиевнең “Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә” романын уку һәм анализлау. | Сәнгатьле уку, автор артыннан бару юлы белән анализлау (аңлатмалар белән уку, кыскача сюжетны сөйләү, әңгәмә, план төзү). | 22.03Б<br>23.03В | |
| 53 | Б.с.үс. Хәдичә белән Зөләйхага чагыштырма характеристика бирү. | | 24.03Б<br>04.04В | |
| 54-55 | З.Бигиев “Гөнаһе кәбаир” романы.Әсәрнең сюжеты.Анализ,төп образларга характеристика. | Эзләнүчән әңгәмә, әсәрне образлар бирелеше аша анализлау (график алым – таблица төзү), аерым 12.04өзекләрне уку, эзләнү төсендәге сорауларга җаваплар бирү, геройларга мөстәкыйль бәя бирү, нәтиҗәләр чыгару. | 05.04Б<br>06.04В<br>07.04Б<br>11.04В | |
| 56 | XIX йөзнең икенче яртысында татар поэзиясе. Гомуми күзәтү. | Лекция, лекцияне язып бару, план-конспект эшләү, нәтиҗәләр чыгару. | 12.04Б<br>13.04В | |
| 57 | М.Акмулланың тормыш юлы, иҗатына күзәтү. “Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе”, “Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән”, | Укытучы сүзе, әңгәмә, сәнгатьле уку, материалларны төп фикерләү рәвешендә язу, аңлатмалар белән уку, нәтиҗәләр чыгару. | 14.04Б<br>18.04В | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | “Башка милләт алга таба барыр булды...” һ.б. әсәрләрен уку һәм фикер алышу. | | | |
| 58 | Акмулла – чичән шагыйрь. Татар шигъриятенә керткән зур өлеше. Иҗатының әһәмияте. | Эзләнүчән әңгәмә, укучыларның чыгыш-ларын тыңлау, шагыйрь хикмәтләренең төп сыйфатларын билгеләү, фәнни чыганаклардан өзекләр уку, Акмулла әсәрләреннән мәкаль-әйтемнәрне, канатлаы сүзләрне билгеләү, мәгънәләрен аңлату, нәтиҗәләр чыгару. Күчермә ысул: аңлатмалар бирү. | 19.04Б<br>20.04В | |
| 59 | Гали Чокрый иҗатына күзәтү. Әсәрләрен уку һәм анализлау. | Укытучы сүзе, сәнгатьле уку, аңлатмалар бирү, нәтиҗәләр чыгару, тел-стиль үзенчәлекләрен күзәтү. | 21.04Б<br>25.04В | |
| 60 | Я.Емельянов иҗаты турында белешмә бирү. “Кайгы”, “Саран бай”, “Олысыманлык” шигырьләрен уку һәм анализлау. | Укытучы сүзе, сәнгатьле уку, аңлатмалар бирү, нәтиҗәләр чыгару, тел-стиль үзенчәлекләрен күзәтү. | 26.04Б<br>27.04В | |
| 61 | Татар драматургиясенең беренче адымнары. Жанр формалашу. Беренче сәхнә әсәрләрендә күтәрелгән мәсьәләләр. | Лекция, укучыларның драма әсәрләрен бәя-анализлау турындагы чыгышлары, фикер алышу, аңлатмалар бирү. | 28.04Б<br>02.05В | |
| 62<br>63 | Г.Ильяси “Бичара кыз”, Ф.Халиди “Рәдде бичара кыз”. Пьесаларны уку, анализлау. | Сәнгатьле уку, автор артыннан бару юлы белән анализлау (кыскача сюжетны сөйләү, аерым өлешләргә анализ бирү), әңгәмә. | 03.05Б<br>04.05В<br>05.05Б<br>09.05В | |
| 64 | IX сыйныфта өйрәнгәннәргә гомуми йомгак. | Укытучы сүзе, укучыларның чыгышлары, контроль соруларга җавап бирү, нәтиҗәләр чыгару | 10.05Б<br>11.05В | |
| 65 | Класстан тыш уку Г.Исхакый “Өч хатын белән тормыш” | Шәрехләп сөйләү, фикерне исбатлау, нәтиҗәләр чыгару. | 12.05Б<br>16.05В | |
| 66 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Контроль сочинение “Мәгърифәтчелек әдәбия-тында тормыш һәм аны үзгәртү юллары”. | Иҗади эш алымы, план төзү, аңлатмалар бирү. | 17.05Б<br>18.05В | |
| 67<br>68 | Кабатлау һәм имтиханга әзерләнү. | Иҗади эш алымы, план төзү, аңлатмалар бирү. | 19.05Б<br>23.05В<br>24.05Б | |

**Укыту-методик комплекты**

**Программа:** Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары. 5-11 нче сыйныфлар/ Ф.Хатипов, А.Әхмәдуллин. К., “Мәгариф”, 2010.
**Дәреслек:** Х.Миңнегулов, Ш.Садретдинов. Борынгы һәм урта гасыр , XIX йөз татар әдәбияты.- К., 2011. 9 нчы сыйныф өчен дәреслек.
***Хрестоматия:*** Әдәбияттан хрестоматия: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен.
*Контроль төре:* ***сорауларга җавап, сәнгатьле сөйләм, сочинение, тест.***

**Файдаланылган әдәбият**

1.Татар мәктәпләрендә татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты, Казан, 2008
2. “Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары” -Азат Әхмәдуллин, Фоат Галимуллин, Флера Ганиева, Фәнис Исламов-Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.
3. Х.Миңнегулов, Ш.Садретдинов. Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбияты.- К., 1998. 9 нчы сыйныф өчен дәреслек.
Әдәбияттан хрестоматия: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен.
4.Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы/Д.Ф.Заһидуллина.- Казан: Мәгариф, 2000
5.Татар балалар әдәбияты/Л.И.Минһаҗева,И.Х.Мияссарова.-Казан:”Хәтер” нәшрияты,2009
6.Татар фольклоры/М.Х.Бакиров.- Казан: Мәгариф, 2008
7.Карурманны чыккан чакта.19 нчы гасыр әдәбияты/З.Р.Вәлиева.Р.М.Миңнуллин һ.б.- Казан: Мәгариф, 2001
8.Ил корабын җил сөрә.20 нче йөз башы татар поэзиясе/И.К.Хәйруллин, Р.М.Миңнуллин һ.б.- . Казан: Мәгариф, 2001
9. Әдәби әсәргә анлиз ясау/ Д.Ф.Заһидуллина,М.И.Ибраһимов,В.Р.Әминева.- . Казан: Мәгариф, 2005
10.Татар балалар поэзиясе антологиясе/Төзүчеләр:Н.Исәнбәт,Г.Рәхим.Р.Кукушкин.-Казан: Татарстан китап нәшрияты,1980

**Фонохрестоматияләр**

1.Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия(5-11сыйныфлар)
2.Х.Туфан шигырьләре
3..А.Арсланов.Яшә,телем
4.Композитор Салих Сәйдәшев

**Электрон методик әсбаплар**

1.Ф.Яруллин тормышы һәм иҗаты
2.Гасырларда калыр батырлык.М.Җәлилнең тормышы һәм иҗаты.
3.Г.Тукай тормыш юлы һәм иҗаты
4.Гаяз Исхакый тормыш юлы һәм иҗаты
5.Композитор А.Ключарев
6.Г.Тукай ,энциклопедия

**Уку елы ахырына 9 нчы сыйныф укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

- тәкъдим ителгән эпик, лирик һәм драматик әсәрләрне уку һәм аларга үз мөнәсәбәтең, бәяң булу;
- сайлап алган әсәрнең (кыскача, тулы, аерым бүлекләренең) эчтәлеген сөйли белү;
- эпик әсәр буенча изложение язу;
- әдәби әсәрнең төрләрен (хикәяләп язылган әсәр, шигырь, пьеса) аера алу;
- сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлын, иҗатын сөйләү;
- әдәби әсәрнең төрен, жанрын исбатлау;
- әдәби әсәрнең темасын, төп фикер – идеясен билгеләү;
- әдәби әсәр героена характеристика бирү;
- эпик әсәрнең бер өлешен образлы сөйләү, цитаталар китерү;
- шигырьне яттан белү яки прозадан өзекне яттан сөйләү
- әсәрнең сәнгать күренеше икәнлеген аңлата алу;
- бер яки берничә әсәр геройларын чагыштырып, уртак һәм үзенчәлекле якларын табу;
- төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү;
- әдәби әсәрнең әһәмиятен, кыйммәтен, үзенчәлекләрен дәлилле итеп аңлата, исбатлый белү;
- сәнгатьле итеп яттан әсәр яки өзекләр сөйләү;
- әдәби әсәрне чор белән бәйләп_характерлау,  чорның уңай сыйфатларын, төп кыйммәтләрен таба белү;
- әсәрдә сюжет  элементларын аера,  композициясен, тел-сурәтләү чараларын күрсәтә, аңлата белү;
- автор фикерен һәм әсәргә үз мөнәсәбәтең, фикереңне аңлату;
- әдәби әсәрләр буенча сочинение язу;
- теге яки бу чордагы  татар әдәбиятының төп проблемаларын бәйләнешле итеп аңлату;
- өстәмә укыган әсәргә, спектакль яки фильмга бәяләмә язу;
- ирекле темага сочинение язу (әдәби материалдан, тормыштан алган тәэсирләреңнән файдаланып).

**Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары**

**Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү**

Иҗади эшнеӊ бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия. Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби-иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

**Сочинениене бәяләү**

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге саклanса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)
2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.
3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

**Сөйләм күнекмәләре ничек бәяләнә**

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле һәм эчтәлеге ягыннан тулы монологик сөйләм төзи алу, бирелгән әсәр яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора белү - "5"ле.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле, әмма эчтәлеге ачылып бетмәгән монологик һәм диалогик сөйләм өчен "4"ле

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле итеп сөйли белмәү, эчтәлекне ачып бетерә алмау, әңгәмәдә өстәмә сораулар бирелгәндә генә катнашу - "3"ле.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән темага монолог та, диалог та төзи алмаганда - "2"ле.

**Анализ күнекмәләре һәм теоретик белемнәр ничек бәяләнә?**

Әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлап, урынлы куллану, анализ нигезле, җавап теоретик яктан югары оештырылган - "5"ле.

Әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлап та аларны куллану барышында аерым төгәлсезлекләр җибәрелсә, анализ эчтәлек сөйләүгә "борыла" - "4"ле.

Әсәрне анализлау яки характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләр куллану, әмма алар күренешкә туры килми, хаталар ясыйсыз; анализ әсәр эчтәлеген кабатлап сөйләүдән генә гыйбарәт - "3"ле.

Әсәрне анализлау яки характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрдән мәгълүматсыз булу күренсә, алар җавапта кулланылмаса, анализ бөтенләй юк - "2"ле.

**Сорауларга җаваплар язу ничек бәяләнә?**

Эшләрне бәяләгәндә, укытучы җавапның тулы, төгәл, дөрес булуына, сөйләмнең стилистик яктан камил, орфографик һәм пунктуацион яктан грамоталы булуына игътибар итә.
Барлык сорауларга да дөрес җавап бирелсә (1 сөйләм хатасы яки 1 пунктуацион хатагыз булырга мөмкин) - "5"ле. Сорауларга дөрес җавап бирелсә, ләкин 2 сөйләм хатасы, 3 орфографик, 2 пунктуацион хата яки 2 сорауга җавап язганда, төгәлсезлек җибәрелсә - "4"ле.
Язма эштә сорауларга җавап бирә белү күнекмәсе сизелә, 3 сөйләм хатасы, 4 орфографик, 5 пунктуацион хатасы бар - "3"ле. Җавапларыгызның яртысы дөрес түгел, сөйләм хаталарыгыз 3 тән артык, 5 орфографик, 6 пунктуацион хатасы бар - "2"ле.

**Файдаланылган әдәбият**

1.Татар мәктәпләрендә татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты, Казан, 2008
2. “Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары” -Азат Әхмәдуллин, Фоат Галимуллин, Флера Ганиева, Фәнис Исламов-Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.
3. Х.Миңнегулов, Ш.Садретдинов. Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбияты.- К., 1998. 9 нчы сыйныф өчен дәреслек.
Әдәбияттан хрестоматия: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен.
4.Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы/Д.Ф.Заһидуллина.- Казан: Мәгариф, 2000
5.Татар балалар әдәбияты/Л.И.Минһаҗева,И.Х.Мияссарова.-Казан:”Хәтер” нәшрияты,2009
6.Татар фольклоры/М.Х.Бакиров.- Казан: Мәгариф, 2008
7.Карурманны чыккан чакта.19 нчы гасыр әдәбияты/З.Р.Вәлиева.Р.М.Миңнуллин һ.б.- Казан: Мәгариф, 2001
8.Ил корабын җил сөрә.20 нче йөз башы татар поэзиясе/И.К.Хәйруллин, Р.М.Миңнуллин һ.б.- . Казан: Мәгариф, 2001
9. Әдәби әсәргә анлиз ясау/ Д.Ф.Заһидуллина,М.И.Ибраһимов,В.Р.Әминева.- . Казан: Мәгариф, 2005
10.Татар балалар поэзиясе антологиясе/Төзүчеләр:Н.Исәнбәт,Г.Рәхим.Р.Кукушкин.-Казан: Татарстан китап нәшрияты,1980

**Фонохрестоматияләр**

1.Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия(5-11сыйныфлар)
2.Х.Туфан шигырьләре
3..А.Арсланов.Яшә,телем
4.Композитор Салих Сәйдәшев

**Электрон методик әсбаплар**

1.Ф.Яруллин тормышы һәм иҗаты
2.Гасырларда калыр батырлык.М.Җәлилнең тормышы һәм иҗаты.
3.Г.Тукай тормыш юлы һәм иҗаты
4.Гаяз Исхакый тормыш юлы һәм иҗаты
5.Композитор А.Ключарев

6.Г.Тукай ,энциклопедия

**Интернет сайтлары**: dzalilova/narod.ru., metodisty.ru›, rusedu.ru, sarvarova.ucoz, magarif-uku.rutugan-tel.blogspot.com›p/blog-page_8553.html